ЛЕНИНОГОРСКИЙ ГОРОДСКОЙ СОВЕТ МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК ЛЕНИНОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ЛЕНИНОГОРСК МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

_17.10.2023_ г.Лениногорск № __160____

«Җир салымы турында» 2020 елның 14 октябрендәге 8 номерлы Лениногорск шәһәр Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Россия Федерациясе Салым кодексының беренче һәм икенче өлешенә, Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында һәм Россия Федерациясе Салым кодексының беренче өлешендәге 78 статьясындагы 1 пунктының икенче абзацының гамәлдә булуын туктатып тору турында» 2023 елның 31 июлендәге 389-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, Лениногорск шәһәр Советы КАРАР БИРДЕ:

1.Лениногорск шәһәр Советының «Җир салымы турында» 2020 елның 14 октябрендәге 8 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешне кертергә:

2 пунктның 3 абзацында «һәм объектлары» сүзләрен «һәм (яисә) объектлары» сүзләренә, «объектка туры килә торган җир кишәрлегенә хокуктагы өлешләр» сүзләрен «күчемсез мөлкәт объектына туры килә торган җир кишәрлеге өлеше» сүзләренә алмаштырырга, «һәм объектларга» сүзләрен «һәм (яисә) объектларга» сүзләренә алмаштырырга.

2. Әлеге карар 2024 елның 1 гыйнварыннан үз көченә керә.

3. Әлеге карарны публикаторда - «Лениногорские вести» газетасында һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз җаваплыгымда калдырам.

Лениногорск шәһәре муниципаль
берәмлеге башлыгы,
Лениногорск шәһәре мэры Р.Г. Хөсәенов